МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.10.2020 г.Казань № 713

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 29 октябрендә 6916 номеры белән теркәлде

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2020 елның 8 октябрендәге 713
номерлы боерыгы белән расланды

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләре уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 21 апрелендәге 219 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 26 сентябрендәге 904 номерлы, 2019 елның 7 маендагы 330 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 1019 номерлы, 2020 елның 2 июлендәге 473 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләре уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон; Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертизаның федераль дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы шәхси тернәкләндерү яисә абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры – 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында егерме бишенче-кырык сигезенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне теркәү, мөрәҗәгать итүче белән халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көнен һәм вакытын килештерү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүгә документларны кабул итүдән баш тарту;

4) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

5) түләүле җәмәгать эшләре (алга таба – җәмәгать эшләре) үткәрүне оештыру;

6) гражданнарны эш бирүче затка җәмәгать эшләрендә катнашу өчен җибәрү;

7) гражданин алга таба мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү;

8) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.»;

3 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 – 3.4.2 пунктларын өстәргә:

«3.4.1. Организмындагы функцияләре бозылган булуын һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен кирәкле, медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле хосусый тернәкләндерү программасы белешмәләре «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм

социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.09.2018 №904, 03.06.2019 №422, 14.11.2019 №1019, 25.06.2020 №460 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «773н номерлы Стандартның 13 пункты; Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертизаның федераль дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы шәхси тернәкләндерү яисә реабилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның рәвешләрен раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан (алга таба – хосусый тернәкләндерү программасы) өземтә, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, шулай ук организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кешенең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңлатыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны»;

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры – 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү, мөрәҗәгать итүче белән халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көнен һәм вакытын һәм дәүләт хезмәте күрсәтү рәвешләрен (аерым яки төркем) килештерү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

мөрәҗәгать итүченең эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, крестьян (фермер) хуҗалыгы оештыруга, үзмәшгульлекне (алга таба – шәхси эшкуарлык) гамәлгә ашыруга әзерлек дәрәҗәсен бәяләү;

эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында карар кабул иткән мөрәҗәгать итүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле белемнәрне һәм күнекмәләрне алу өчен бизнес-план әзерләүне оештыру;

юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда бер бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү (алга таба – дәүләт теркәвенә алынганда бер бирелә торган финанс ярдәме) һәм тиешле дәүләт теркәвен узу өчен документлар әзерләүгә бер бирелә торган финанс ярдәме (алга таба – документлар әзерләүгә бер бирелә торган финанс ярдәме) бирү;

Техник хаталарны (язу хаталарын, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны яисә шуңа охшаш хаталарны) төзәтү.»;

3 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.3.5 – 3.3.6 пунктларын өстәргә:

«3.3.5. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Организмындагы функцияләре бозылган булуын һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен кирәкле, медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле хосусый тернәкләндерү программасы белешмәләре «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.3.6. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.3.5 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.»;

3.4.2 пунктның 2 пунктчасында «2.7 пунктында» сүзләрен «2.8 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 – 3.8.1 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.06.2016 №337, 26.09.2018 №904, 05.03.2019 №158, 07.05.2019 №330, 14.11.2019 №1019, 29.06.2020 №468 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте

күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры – 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктала хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне теркәү, мөрәҗәгать итүче белән халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көнен һәм вакытын килештерү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүгә документларны кабул итүдән баш тарту;

4) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

5) гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру;

6) балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыру;

7) эшсез гражданнарны һәм эшсез чыгарылыш укучыларын вакытлыча эшкә урнаштыру;

8) вакытлыча эшкә урнаштыру өчен гражданнарны эш бирүче янына җибәрү;

9) гражданин алга таба мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү;

10) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.»;

3 нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 – 3.4.2 пунктларын өстәргә:

«3.4.1. Организмындагы функцияләре бозылган булуын һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен кирәкле, медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле хосусый тернәкләндерү программасы белешмәләре «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек

системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә сорала торган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия. Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.».

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 №328, 14.11.2019 №1018, 31.03.2020 №216, 23.06.2020 №454 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.14 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2015 елның 21 июлендә теркәлгән, теркәлү номеры – 38115) белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

6.4.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.1. Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.»;

6.6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.6.1. Күпфункцияле үзәк белгече халыкның мәшгульлек үзәгебелән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.».